Чыгу көне: 30.10.2021







**Бу чыгарылышта:**


| | |
|---|---|
| Укытучылар көне белән, хөрмәтле | 1 |
| Мәктәп яңалыклары | 2-4 |


Хөрмәтле укытучылар!!!

Сез – безнең иң кадерләләребез, үрнәк алырлык кешеләребез. Сез биргән белемнәр, сезнең үгет-нәсихәтегез безгә бүгенге авыр тормышта да дөрес юлдан тайпылмыйча, гел алга барырга ярдәм итә. Үзегезгә дә укучыларыгызның рәхмәтләренә төренеп, аларның ярдәмен тоеп яшәргә насыйп булсын.

Атачак таңнарыгыз – аяз, туасы көннәрегез – кояшлы, төннәрегез – тыныч, сәламәтлегегез нык булсын. Без - барлык мәктәп укучылары, сезне профессиональ бәйрәмегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Сезгә исәнлек-саулык, озын гомер, җан тынычлыгы телибез. Изге эшләрегез безнең өчен, балалар өчен. Шул эшләр башкарган хезмәтегездә иминлек телибез сезгә. Укытучы – изге бер сүз ул. Һәр кеше моның мәгънәсенә төшенә. Укытучы бөтен көчен биреп балаларга аң - белем, тәрбия бирергә тырыша. Сезнең фидакарь хезмәтегез, югары һөнәри осталыгыгыз, сабыр һәм ярдәмчел булуыгыз өчен тирән ихтирамыбызны белдерәбез.

**Игътибар итегез!**

Кадерле укучылар, тиздән, бик тиздән көзге каникуллар башланачак.

Сезгә матур яллар телибез!







**“Макулатура тапшыр - агачны коткар! " акциясе.**

15 нче октябрь көнендә безнең мәктәптә макулатура җыю буенча " Макулатура тапшыр – агачны коткар!»акцисе үтте. Акция алдыннан сыйныф җитәкчеләре балаларга һәр кешенең урманнарны, экологияне һәм планетабызның табигый матурлыгын саклау эшенә өлеш кертә алуы турында сөйләделәр. Мәсәлән, һәркем макулатура тапшыра ала-бу кечкенә булса да, тере табигатьне саклауга мөһим өлеш кертү. Акциянең төп максаты- әйләнә-тирә мөһитне саклауга омтылыш, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

Акциядә 68 сыйныф катнашты. Укучыларга ярдәмгә аларның әти-әниләре, бабайлары һәм әбиләре килгән иде. Уртак көч белән 2465 кг макулатура җыелды. Ә, билгеле булганча, 1 тонна макулатура якынча 10 агачның гомерен саклап кала.

Акциядә катнашучыларның барысына да тырышлыклары өчен рәхмәт!

Газета хәбәрчеләре

Илебез буенча октябрь ае башында **Өлкәннәр көне** уздырыла. Төрле җирләрдә өлкәннәрне котлаулар, бүләкләүләр, искә алулар бара.

Өлкән кешеләр – безнең әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз. Алар бик күп авырлыклар күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган кешеләр. Аларны өлкән булган өчен генә түгел, ә әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз булган өчен дә хөрмәт итәргә тиешбез.

Рәхмәт сезгә, бу дөньяда куйган хезмәтләрегез, кылган изгелекләрегез өчен. Без, яшьләр, сезнең киңәшләрегездән тайпылмабыз, үрнәк булырга тырышырбыз .

Мәрхәмәт, кешелеклелек,

Изге уй, яхшы теләк.

Җирдә яшәүче һәркемгә

Һәр даим зарур, кирәк.

Өмет белән яшик, тик сынатмыйк,

Ходай гына бирсен сабырлык.

Бардыр әле җирдә саф орлык.

## Мәктәп президентын сайлау

19 нчы октябрь көнне мәктәбебездә мәктәп президенты сайлаулары булып узды

Президентлыкка кандидатлыкка үз кандидатурасын 3 укучы белдерде:

Пеньков Ратмир Евгеньевич (8А кл.)

Маркелов Алексей Николаевич (10 Б кл.)

Галиуллин Арслан

Олегович (11 В кл.)

Укучылар һәм укытучыларның сайлауларыннан соң нәтиҗә билгеләнде.

Җиңүче: Маркелов Алексей Николаевич (10 Б кл.)

Мәктәбебез



Октябрь аенда мәктәбебез “Дөнья җәмәгатьчелегендә яшәү өчен белем бирү буенча координацияләнгән эксперименталь чаралар схемасы” проектлар кысасында Чебоксар укучылары делегацияләрен кабул итте.



# «Дүрт аяклы дусларыбыз”га ярдәм

Игелекле эшләр безнең мәктәп укучыларының яхшы гадәтенә әверелде. Һәр көз, менә берничә ел инде без Ковал авылындагы хуҗасыз калган хайваннар приютына булышабыз. Барлык укытучыларга, укучыларга һәм ата-аналарга дөрес тәрбия бирүләре, кечкенә дусларыбызга карата мәхәббәт һәм мәрхәмәт тәрбияләүләре өчен рәхмәт.

Курняева Юлия




Редакциянең адресы:
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
Тираж – 50 экз.

Баш мөхәррир һәм дизайнер:
Габдуллаҗанова А.Ф.

Редколлегия әгъзалары:
Сафина Камилла, Соколова София, Овезова Ләйлә, Курняева Юлия